КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 7 сентябрь г.Казань № 1099

2024 – 2026 елларга айлык акчалата түләүләр һәм түләүләрнең башка төрләре турында

«Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 ел, 8 декабрь, ТРЗ-63 нче Татарстан Республикасы Законы һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында халыкның кайбер категорияләренә акчалата түләүләр, пособиеләр, субсидияләр һәм стипендияләр бирү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2004 ел, 17 декабрь, 542 нче карары нигезендә билгеләнгән айлык акчалата түләүләрне һәм түләүләрнең башка төрләрен индексацияләү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Түбәндәгеләр дип билгеләргә:

«Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 ел, 8 декабрь, ТРЗ-63 нче Татарстан Республикасы Законының 4 – 8 статьяларында күздә тотылган айлык акчалата түләүләрне һәм түләүләрнең башка төрләрен индексацияләү коэффициентларын түбәндәге күләмнәрдә:

2024 елның 1 гыйнварыннан – 1,04;

2025 елның 1 гыйнварыннан – 1,04;

2026 елның 1 гыйнварыннан – 1,04;

бу карарның кушымтасы нигезендә 2024 – 2026 елларга айлык акчалата түләүләр һәм түләүләрнең башка төрләре күләмнәрен.

2. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына бу карарның 1 пунктындагы атынчы абзацында каралган 2024 – 2026 елларга айлык акчалата түләүләр һәм түләүләрнең башка төрләре күләмнәрен билгеләүгә бәйле мәсьәләләрне аңлату эшен үткәрергә.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2023 елга айлык акчалата түләүләр һәм түләүләрнең башка төрләре турында» 2022 ел, 1 сентябрь, 934 нче карары 2024 елның 1 гыйнварыннан үз көчен югалткан дип танырга.

4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2023 ел, 7 сентябрь, 1099 нчы
карарына кушымта

2024 – 2026 елларга айлык акчалата түләүләр һәм
түләүләрнең башка төрләре күләмнәре

| Түләү төре | Түләү күләме, сум | | |
|---|---|---|---|
| | 2024 ел | 2025 ел | 2026 ел |
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| Айлык акчалата түләү:<br>пенсияләре «Иминият пенсияләре турында» 2013 елның 28 декабрендәге 400-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында» 2001 елның 17 декабрендәге 173-ФЗ номерлы һәм «Россия Федерациясендә дәүләт пенсия тәэминаты турында» 2001 елның 15 декабрендәге 166-ФЗ номерлы федераль законнар нигезендә билгеләнгән яки 2018 елның 31 декабренә карата әлеге федераль законнарда каралган пенсия билгеләү шартларына туры килә торган, уртача айлык кереме күләме 20 000,0 сумнан артмаган хезмәт ветераннарына; | 605,0 | 630,0 | 656,0 |
| «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 5 статьясындагы 1 пунктта каралмаган башка нигезләр буенча пенсияләр алучы яисә эш (хезмәт) өчен гомерлек түләү алучы 60 һәм 55 яшькә (шул ук эзлеклелектә ир-атлар һәм хатын-кызлар) җиткән | 605,0 | 630,0 | 656,0 |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| хезмәт ветераннарына, әгәр дә аларның уртача айлык керемнәре күләме 20 000 сумнан артмаса; | | | |
| «Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре турында» 2011 елның 10 октябрендәге 74-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре белән бүләкләнгән һәм картлык буенча яки тиешле еллар эшләгән өчен пенсия билгеләү өчен кирәкле стажы булган, пенсияләре «Иминият пенсияләре турында» 2013 елның 28 декабрендәге 400-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында» 2001 елның 17 декабрендәге 173-ФЗ номерлы һәм «Россия Федерациясендә дәүләт пенсия тәэминаты турында» 2001 елның 15 декабрендәге 166-ФЗ номерлы федераль законнар нигезендә билгеләнгән яки 2018 елның 31 декабре хәленә карата әлеге федераль законнарда каралган пенсияне билгеләү шартларына туры килә торган затларга; | 605,0 | 630,0 | 656,0 |
| «Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре турында» 2011 елның 10 октябрендәге 74-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре белән бүләкләнгән һәм картлык буенча яки тиешле еллар эшләгән өчен пенсия билгеләү өчен кирәкле стажы булган, «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 5[1] статьясындагы 1 – 3 пунктларда каралмаган башка нигезләр буенча пенсияләр алучы яисә эш (хезмәт) өчен гомерлек түләү алучы 60 һәм 55 яшькә җиткән (шул ук эзлеклелектә ир-атлар һәм хатын-кызлар) затларга; | 605,0 | 630,0 | 656,0 |
| 1941 елның 22 июненнән 1945 елның 9 маена кадәрге чорда | 902,0 | 939,0 | 977,0 |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| кимендә алты ай тылда эшләгән затларга (СССРның вакытлыча оккупацияләнгән территорияләрендә эшләү чоры керми); | | | |
| Бөек Ватан сугышы чорында фидакарь хезмәт өчен СССР орденнары яки медальләре белән бүләкләнгән затларга; | 902,0 | 939,0 | 977,0 |
| акланган гражданнарга; | | | |
| сәяси репрессияләрдән зыян күргән дип танылган гражданнарга; | 902,0 | 939,0 | 977,0 |
| опекага (попечительлеккә), башка гаиләләргә тәрбиягә бирелгән ятим балаларга һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларга: | 757,0 | 788,0 | 820,0 |
| мәктәпкәчә яштәге балаларга | 10 740,0 | 11 170,0 | 11 617,0 |
| мәктәп укучыларына | 12 384,0 | 12 880,0 | 13 396,0 |
| Транспортта йөрүгә субсидия: | | | |
| төп белем бирү программалары буенча белем алучы ятим балаларга, ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларга һәм ятим балалар, ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар арасыннан булган затларга һәм уку чорында атасын да, анасын да яки атасын йә анасын югалткан затларга; | 369,0 | 384,0 | 400,0 |
| гаилә составында 18 яшькә кадәрге өч һәм аннан күбрәк баласы (тәрбиягә алынган баланы кертеп) булган гражданнарның гомуми белем бирү оешмаларында һәм һөнәри белем бирү оешмаларында белем алучы балаларга укуы тәмамланганга кадәр, әмма иң күбе 18 яше тулганчы | 369,0 | 384,0 | 400,0 |
| 18 яшькә кадәр өч һәм аннан күбрәк балалы гаиләләрдән булган (тәрбиягә алган гаиләләрне кертеп) алты яшькә кадәрге баласы өчен дару чаралары сатып алуга субсидия | 164,0 | 171,0 | 178,0 |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| Пенсияләре «Иминият пенсияләре турында» 2013 елның 28 декабрендәге 400-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында» 2001 елның 17 декабрендәге 173-ФЗ номерлы һәм «Россия Федерациясендә дәүләт пенсия тәэминаты турында» 2001 елның 15 декабрендәге 166-ФЗ номерлы федераль законнар нигезендә билгеләнгән пенсионерларга, 60 һәм 55 яшькә (шул ук эзлеклелектә ир-атлар һәм хатын-кызлар) җиткән гражданнарга , 2018 елның 31 декабре хәленә карата әлеге федераль законнарда каралган пенсия билгеләү шартларына туры килә торган, әмма 60 һәм 55 яшькә (шул ук эзлеклелектә ир-атлар һәм хатын-кызлар) җитмәгән, Татарстан Республикасында яшәгән, Россия Федерациясенең яки Татарстан Республикасының башка норматив хокук актлары буенча социаль ярдәм күрсәтү чараларына хокукы булмаган, мөлкәт белән тәэмин ителеш дәрәҗәсе «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына кушымтада билгеләнгән гаиләнең (гражданның) мөлкәт белән тәэмин ителеш дәрәҗәсеннән түбәнрәк булган һәм мөрәҗәгать итү көненә уртача айлык керемнәре күләме 20 000 сумнан артмаган гражданнарга транспортта йөрүгә айлык акчалата түләү | 605,0 | 630,0 | 656,0 |
| Дәүләт һәм муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында төп гомуми һәм урта гомуми белем бирүнең мәгариф программалары буенча белем алучыларны, шулай ук уку чорында дәүләт һәм муниципаль һөнәри белем бирү оешмаларында белем алучыларны туклану белән тәэмин итү | 9,2 (көн саен) | 9,6 (көн саен) | 10,0 (көн саен) |

_______________________